# 6 нчы март
# Сыйныф эше

Тема:

# Дәреснең темасы



# Туган көн

# Туган көнгә ничек чакырырга?




- Гафу үтенергә
- Исәнләшергә
- Ягымлы итеп сөйләшергә
- Рәхмәт әйтергә

# Балалар, очрашкач, бер-берсенә нинди сүзләр әйтәләр?



- Исәнмесез!
- Исәнме!
- Туган көнең белән!
- Туган көнең котлы булсын!
- Бәхетле бул!



# "Без чакырдык кунаклар"





Ләйсәннең туган көненә
Без чакырдык кунаклар;
Кунакларның килүенә
Без пешердек коймаклар.
Коймакларга карасаң,
Менә шулай күпергән.
Менә шулай җәелгән,
Менә шулай кысылган.
Коймагыңны майлап ал,
Теләгәнең сайлап ал.

# Туган көнгә нәрсә бүләк итәргә?











- Үз кулларың белән ясаган әйбер (открытка, гербарий, чиккән кульяулык).
- Үзең үстергән чәчәкләр.
- Китап.


# Кунакта нинди уеннар уйнап була?

- Шахмат
- Домино
- Шашка
- Мозаика
- Лото
- Йөзек салыш
- Мәкаль әйтеш













# Мин башлыйм, син дәвам ит!

- Кунак булсаң,

тыйнак бул.

- Инә дә бүләк,


дөя дә бүләк.

- Киемгә карап каршы алалар,

акылга карап озаталар.


- Матурлык күлмәк белән сәдәптә түгел,

оят белән әдәптә.



# Бии итек, читекләр

Гармун уйныйм, гармун уйныйм,
Һаман гармун уйныйм мин.
Минем кебек шәп гармунчы
Юктыр диеп уйлыйм мин.
Учларыңны шапылдатып,
Чәчләреңне сыпыр да,
Тыпыр-тыпыр,тыпыр-тыпыр,
Тыпыр-тыпыр тыпырда.
Гармун уйныйм, гармун уйныйм,
Һаман гармун уйныйм мин.
Остарып җиткәч барсын да
Биетергә уйлыйм мин.



# Өстәл янында үз-үзеңне ничек тотарга?



1. Өстәл янында башыңа киеп утырма.
2. Өстәл өстенә терсәкләреңне куйма.
3. Ашаганда сөйләшмә.
4. Тавышсыз ашарга тырыш.
5. Ипине зур кабып ашама.
6. Пычактан ашама.
7. Ерактагы азыкка өстәл аша сузылма, әдәпле генә итеп,алып бирүләрен сора.
8. Азыкны сайлап алма.
9. Компотның җимеш орлыкларын төкермә.
10. Ашаганнан соң, чәнечке белән пычакны тәлинкәгә куй.
11. Кашыгыңны чынаяк яки стакан эчендә калдырма.
12. Ашаганда укыма.
13. Иреннәреңне сөртү өчен кечкенә тастымалдан(салфеткадан)файдалан.

# "Туган көн" җыры

Бәйрәмнәрне бик яратам,
Матур алар һәрберсе.
Арасында иң яраткан-
Була икән тик берсе.

Җырлыйсым килә бүген,
Биисем килә бүген,
Чөнки,чөнки, чөнки нәкъ-
Бүген бит туган көнем.
Чөнки,чөнки, чөнки нәкъ-
Бүген бит туган көнем.

